Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2025 елның 3 апреле № 6

## Бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Югары Ырга авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Балык Бистәсе муниципаль районының Югары Ырга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы", Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Югары Ырга авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Югары Ырга авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 4 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Югары Ырга авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Югары Ырга авылы, М.Җәлил ур., 18 йорт; Яңа Ырга авылы, Мәктәп урамы, 48 йорт.
3. Карар ул басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге башлыгы Р.Н.Багаутдинов